КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 август г.Казань № 706

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2018 ел, 9 апрель, 218 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә, 3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.4 Инспекция үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.01*);

--------------------------------

* Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 02 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча кодны билгеләү.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01*);

Татарстан Республикасының ведомстволарга караган дәүләт мәгълүмат ресурсларын булдыру белән идарә итү (01.15.01.2*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01*);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03*);

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15*);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән – бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты) белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.1*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

билгеләнгән тәртиптә хезмәт белән идарә итү (01.13*), шул исәптән хезмәт өчен түләүне, хезмәт мөнәсәбәтләрен, турыдан-туры хезмәткә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.13.01*);

хезмәтне саклау белән идарә итү (01.13.02*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01*);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03*);

Татарстан Республикасының Архив эшләре буенча дәүләт комитеты белән – архив эшләре белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03*);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән – социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән –

гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.01*);

муниципаль торак контроле органнары белән – «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә;

Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 1.1 өлеш белән билгеләнгән вәкаләтләр бирелгән җирле үзидарә органнары белән – төзелә торган килешүләр нигезендә;

күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үзҗайга салынучы оешмалар яки оештыру-хокук формасын бәйсез рәвештә юридик затларның яки күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрләр бүтән берләшмәләре белән – килешүләр нигезендә;

торак милекчеләре иптәшлекләре берләшмәләре (ассоциацияләр, берлекләр), торак, торак-төзелеш һәм бүтән махсуслашкан кулланучылар кооперативлары белән – килешүләр нигезендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин